| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.01.2023 Казан ш № 1

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^{1}$ статьясының 1 пункты нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.

2.Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары Э.Н.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 09.01.2023 ел, №1 боерыгына кушымта

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә (алга таба – Учреждение) дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанс яктан тәэмин итүгә бәйле булмаган максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү механизмын билгели.

2. Субсидияләр (алга таба – Субсидия) Учреждениегә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасын раслау турында » 23.12.2013 ел, № 1023 карары белән расланган 2014-2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасын (алга таба – дәүләт программасы) гамәлгә ашыру кысаларында чаралар уздыруга бирелә. Субсидияне бирү максатлары әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә Субсидияләр исемлеге (алга таба – Исемлек) нигезендә билгеләнгән.

3. Учреждениегә субсидияләр, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак, тиешле финанс елына (тиешле финанс елына һәм план чорына) Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Субсидияне алу өчен Учреждение Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә форма буенча Учреждение тарафыннан рәсмиләштерелгән Субсидия бирүгә гариза;

аңлатма язуын, анда Исемлектә күрсәтелгән максатларга бюджет акчаларын бирү зарурлыгын нигезләү, шул исәптән Субсидия суммасын исәпләү-нигезләү, шулай ук тиешле эшләрне башкаруга (хезмәтләрне күрсәтүгә), чаралар уздыруга, мөлкәт сатып алуга (күчемсез мөлкәттән тыш) башлангыч смета, шулай ук тәэминатчыларның (подрядчыларның, башкаручыларның) тәкъдимнәре, статистика белешмәләре һәм (яки) башка мәгълүмат була;

ремонт (реставрация) ясалырга тиешле объектлар исемлеге, мондый объектларны тикшерү акты һәм дефектлар исемлеге, субсидия бирүнең максаты башка максатларга ремонт үткәрү булса, чыгымнарның беренчел сметасы;

Субсидия бирүнең максаты чаралар, шул исәптән конференцияләр, симпозиумнар, күргәзмәләр уздыру булса, чаралар программасы;

Субсидия бирү максаты мөлкәтне сатып алу булса, сатып алуга планлаштырылган мөлкәт турында мәгълүмат;

түләүләрне алучылар булып торган физик затларның саны (уртача еллык саны) һәм мондый түләүләрнең төрләре турында мәгълүмат, әгәр Субсидия бирү максаты булып әлеге түләүләрне башкару торса;

субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзү планлаштырыла торган айдан алдагы айның 1 нче көненә булган торышында Учреждениенең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен, пеняларны, штрафларны, процентларны түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләренең булмавын раслый торган салым органы белешмәсе;

Килешү төзү планлаштырыла торган айдан алда килгән айның 1 нче көненә Учреждениенең, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарып бирү түләү вакыты узган бурычларының булмавы турында җитәкче һәм баш бухгалтер, вәкаләтле башка зат тарафыннан имзаланган белешмә;

Субсидия бирү максатына карап, башка мәгълүмат.

Документлар Учреждение тарафыннан кәгазьдә тапшырыла. Гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар бер папкага (том) тегелергә, битләредә номерлары күрсәтелергә, Учреждение җитәкчесенең үз кулы белән имзаланырга һәм мөһер белән беркетелергә тиеш.

Барлык документлар да төгәл бастырылган булырга тиеш. Чистартылган һәм төзәтмәләр кертелгән урыннар рөхсәт ителми, Учреждение җитәкчесенең мөһере һәм шәхси имзасы белән таныкланган төзәтмәләрдән тыш.

5. Субсидия алу өчен документлар Министрлыкка кергән көнне теркәлә.

Документларны карау һәм Субсидия бирү турында карар кабул итү Министрлыкка кергән көннән алып 10 эш көне эчендә башкарыла.

Кабул ителгән карар турында Министрлык карар кабул ителгәннән соң 3 эш көне дәвамында Учреждениегә хат белән хәбәр итә.

6. Учреждение Килешү төзү планлаштырыла торган айдан алда килгән айның 1 нче көненә түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

Учреждениенең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеняларны, штрафларны түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмаска тиеш;

Учреждениенең, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарып бирү түләү вакыты узган бурычлары юк.

7. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

Учреждение тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Учреждение тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

бюджет законнары нигезендә Министрлыкка җиткерелгән, тиешле финанс елына (тиешле финанс елына һәм план чорына) субсидияләр бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитларының тиешле күләмдә булмавы.

Министрлыкның Субсидия бирүдән баш тарту турындагы карары әлеге карар кабул ителгәннән соң 2 эш көне дәвамында Учреждениегә хат белән тапшырыла.

Баш тартуга нигез булган кисәтүләрне бетергән очракта, Учреждение субсидия алу өчен кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

8. Субсидия Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән типик форма нигезендә Министрлык һәм Учреждение арасында төзелә торган Килешү нигезендә бирелә. Министрлык Субсидия бирү турында карар кабул ителгәннән соң 5 эш көне эчендә Субсидия алучыга гаризада күрсәтелгән электрон почта адресына Килешү проектын җибәрә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

Субсидияне бирү максатлары;

Субсидияне бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре;

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планы;

Субсидиянең күләме;

Субсидияне күчерү вакытлары (графигы);

финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Субсидия торган чыгымнар турында хисап, Субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешү турында хисап, Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планын гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары;

Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органының Учреждение тарафыннан Субсидияне бирү максатлары һәм шартлары үтәлешенә тикшерү үткәрүгә хокукы;

Министрлык тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнарының башка вәкаләтле органнары тарафыннан әлеге Тәртиптә һәм төзелгән килешүләрдә билгеләнгән максатчан субсидия бирү максатларын һәм шартларын бозу фактлары ачыкланган очракта, Учреждение файдаланган суммаларны кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

Килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән Министрлыкка, бюджет акчаларын алучы буларак, Субсидия бирү өчен элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары кимегән очракта да;

Министрлык карары буенча Килешүне берьяклы тәртиптә вакытыннан алда туктату өчен нигезләр, шул исәптән Учреждениене үзгәртеп кору (кушылу рәвешендә үзгәртеп корудан тыш) яки бетерүгә бәйле рәвештә дә;

Учреждение тарафыннан хокукый актта һәм (яки) Килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү максатлары һәм шартлары бозылган очракта;

Учреждение тарафыннан Килешүне берьяклы тәртиптә өзүнең тыелган булуына бәйле рәвештә;

Килешү якларының башка хокуклары һәм бурычлары һәм Килешүләрне гамәлгә ашырганда аларның үзара хезмәттәшлек итү тәртибе.

Зарурлык булганда, Килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән Субсидия бирү турындагы килешүнең (шартнамәнең) типлаштырылган формасына кушымтада китерелгән форма буенча килешүне өзү турында өстәмә килешү төзелә.

9. Субсидия билгеләнгән тәртиптә Учреждениенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган аерым шәхси счетына күчерелә.

10. Субсидиянең күләме Учреждение тапшырган документлар нигезендә, Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында

тиешле финанс елына һәм план чорына каралган бюджет ассигнованиеләре һәм билгеләнгән тәртиптә Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә, субсидия бирү максатына бәйле рәвештә хокукый актларда һәм башка документларда билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып билгеләнә, субсидия күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән очраклардан тыш.

Министрлык түбәндәге очракларда Субсидия күләмен үзгәртергә хокуклы:

тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында яисә Министрлыкка каралган бюджет йөкләмәләре лимитларында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмен арттыру яисә киметү очрагында, аларны гамәлгә ашыруга Субсидия бирелә торган максатларга (чараларга, эшләр составына) кирәкле төзәтмәләрне исәпкә алып;

тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында тиешле бюджет ассигнованиеләре булганда һәм Учреждение нигезле гариза тапшырган очракта, Учреждениенең өстәмә чыгымнарны гамәлгә ашыру ихтыяҗы булганда;

Субсидия күләмен киметү кирәк булган очракта, әгәр Учреждение тарафыннан Субсидия бирү максатларына ирешүне тәэмин итүгә тотылган чыгымнар Килешүдә каралган күләмнән азрак булса, шулай ук Министрлык тарафыннан Учреждениедә Субсидия акчаларының әлеге экономия суммасында экономиясе булуы турында карар кабул ителгән очракта;

Субсидия бирү буенча чыгым йөкләмәләрен билгели торган норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертелгән очракта.

11. Субсидияне бирү максатларына карап, аны бирү нәтиҗәләре:

субсидия чараларны үткәрүгә бирелгән очракта, үткәрелгән чаралар саны;

Учреждение белгечләре хезмәтенә түләүләрне башкаруга бирелгән субсидия исәбенә кабул ителгән йөкләмәләр күләме (100 процент күләмендә);

субсидия мөлкәт сатып алуга бирелгән очракта, сатып алынган мөлкәт объектлары саны.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү вакыты – Субсидия бирелгән елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

12. Учреждение Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

хисап аеннан соңгы айның 10нчы көненнән соңга калмыйча, ай саен, финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып Субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турындагы хисаплылык;

ел саен, агымдагы финанс елының 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча, Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап һәм финанс хисап елы өчен Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планын тормышка ашыру турында хисап.

Хисапларның формалары Килешүдә билгеләнә.

13. Хисап елында кулланылмаган акчаларны әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга җибәрү ихтыяҗы булган очракта, Учреждение Министрлыкка хисап елыннан соң килә торган елның 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча, мондый ихтыяҗны нигезләп, мәгълүмат бирә.

Министрлык әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны оешмадан алганнан соң, биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан

Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, агымдагы финанс елында хисап финанс елында кулланылмыйча калган Субсидияне юнәлдерү ихтыяҗы булуы яки булмавы турында карар кабул итә.

Агымдагы финанс елына хисап финанс елында кулланылмый калган Субсидияне юнәлдерү ихтыяҗы турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык һәм Учреждение арасында, мондый карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта, Килешүгә өстәмә килешү төзелә.

Хисап елында кулланылмаган Субсидия Татарстан Республикасы бюджеты кеременә хисап елыннан соң килә торган елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча, Министрлык тарафыннан әлеге акчаларга ихтыяҗ булуы турында карар кабул ителү очракларыннан тыш, кире кайтарылырга тиеш.

14. Агымдагы финанс елында финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып Субсидия (алга таба – дебиторлык бурычын кире кайтарудан алынган акчалар) торган, Учреждение тарафыннан элегрәк кайтарылган түләүләрдән килгән акчалар булган очракта, Учреждениенең финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып дебиторлык бурычын кире кайтарудан алынган акчалар торган, үтәлмәгән йөкләмәләре булуы турындагы мөрәҗәгате, шулай ук Учреждениенең әлеге йөкләмәләренең булуы һәм күләме турында раслый торган документлар (документларның күчермәләре) (физик затларга булган түләүләр буенча йөкләмәләрдән кала) нигезендә Министрлык аларны Учреждение тарафыннан әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен файдалану турында карар кабул итә.

Министрлык Учреждениедән әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән соң өч эш көне узганчы агымдагы финанс елында дебиторлык бурычларын кире кайтарудан алынган кулланылмаган акчаларны әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен юнәлдерү зарурлыгы булуы яки булмавы турында карар кабул итә.

15. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы Учреждениегә субсидия бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлүгә карата мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

Акчаларны максатчан тотмау Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә җаваплылык китереп чыгара.

Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы тарафыннан уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә ачыкланып, Учреждение субсидия биргәндә билгеләнгән максатларны һәм шартларны үтәмәгән, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешелмәгән очракларда, субсидия тиешле таләп Учреждение тарафыннан алынган көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көнлек чорда Учреждение тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарып бирелергә тиеш.

Субсидия акчаларын Учреждение тарафыннан кире кайтару чорлары бозылган очракта, Министрлык әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән чор беткән көннән соң 30 көнлек чорда законнарда билгеләнгән тәртиптә субсидия акчаларын Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү чараларын күрә.

Татарстан Республикасы
дәүләт бюджет һәм автоном
учреждениеләренә башка
максатларга финанс яктан
тәэмин итү чыганагы булып
Татарстан Республикасы
бюджеты акчалары торган
субсидияләрне бирү күләмен
һәм шартларын билгеләү
тәртибенә 1 нче кушымта
_____________ № _________

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанс яктан тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга Субсидияләр исемлеге

| т/с | Субсидиянең атамасы | Субсидияне бирү максаты | Субсидия күләмен исәпләү |
|---|---|---|---|
| 1 | Дәүләт автоном яки бюджет учреждениесе уставында каралган эшчәнлегенең төп төрләрен тәэмин итү максатларында төп чараларны сатып алу | 2014-2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасы кысаларында каралган дәүләт автоном яки бюджет учреждениесе эшчәнлегенең төп төрләрен тәэмин итү максатларында төп чараларны (күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) сатып алуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү | Чыгымнар сметасы һәм финанс-икътисадый нигезләү, Субсидияләр бирү өчен Министрлыкка каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бүленә, Субсидияләр күләме бюджет турындагы закон (карар) белән, Татарстан Республикасы Президенты карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән очраклардан тыш. |
| 2 | Проект-смета документларын эшләү һәм экспертизаны да кертеп, мөлкәтне капиталь ремонтлау | 2014-2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасы кысаларында оператив идарә яисә түләүсез файдалану хокукында булган биналарны капиталь | Чыгымнар сметасы һәм финанс-икътисадый нигезләү, Субсидияләр бирү өчен Министрлыкка каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бүленә, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | ремонтлауга бәйле хезмәтләр күрсәтүгә, эшләр башкаруга шартнамәләрне түләүгә бәйле чыгымнарны гамәлгә ашыру | Субсидияләр күләме бюджет турындагы закон (карар) белән, Татарстан Республикасы Президенты карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән очраклардан тыш. |
| 3 | Проект-смета документациясен эшләүне һәм экспертизаны кертеп, мөлкәтне агымдагы ремонтлау | 2014-2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасы кысаларында оператив идарә яисә түләүсез файдалану хокукында булган биналарны агымдагы ремонтлауга бәйле хезмәтләр күрсәтүгә, эшләр башкаруга шартнамәләрне түләүгә бәйле чыгымнарны гамәлгә ашыру | Чыгымнар сметасы һәм финанс-икътисадый нигезләү, Субсидияләр бирү өчен Министрлыкка каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бүленә, Субсидияләр күләме бюджет турындагы закон (карар) белән, Татарстан Республикасы Президенты карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән очраклардан тыш. |
| 4 | Аварияле (гадәттән тыш) хәл килеп чыккан очракта, торгызу эшләрен үткәрү | 2014-2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасы кысаларында аварияле (гадәттән тыш) хәл килеп туган очракта, торгызу эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны гамәлгә ашыру | Чыгымнар сметасы һәм финанс-икътисадый нигезләү, Субсидияләр бирү өчен Министрлыкка каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бүленә, Субсидияләр күләме бюджет турындагы закон (карар) белән, Татарстан Республикасы Президенты карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән очраклардан тыш. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 | Янгынга каршы чаралар үткәрү һәм (яки) янгынга каршы инвентарь сатып алу | 2014-2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасы кысаларында янгынга каршы чаралар уздыруга һәм (яки) янгынга каршы инвентарь сатып алуга бәйле чыгымнарны гамәлгә ашыру | Чыгымнар сметасы һәм финанс-икътисадый нигезләү, Субсидияләр бирү өчен Министрлыкка каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бүленә, Субсидияләр күләме бюджет турындагы закон (карар) белән, Татарстан Республикасы Президенты карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән очраклардан тыш. |
| 6 | Ягып җылыту сезонына әзерлек кысаларында чаралар үткәрү | 2014-2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасы кысаларында ягып җылыту сезонына әзерлек кысаларында чаралар уздыруга чыгымнарны гамәлгә ашыру | Чыгымнар сметасы һәм финанс-икътисадый нигезләү, Субсидияләр бирү өчен Министрлыкка каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бүленә, Субсидияләр күләме бюджет турындагы закон (карар) белән, Татарстан Республикасы Президенты карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән очраклардан тыш. |
| 7 | Социаль әһәмияткә ия чаралар уздыру | 2014-2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасы кысаларында социаль әһәмияткә ия чараларга чыгымнарны финанс белән тәэмин итү | Чыгымнар сметасы һәм финанс-икътисадый нигезләү, Субсидияләр бирү өчен Министрлыкка каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бүленә, Субсидияләр күләме бюджет турындагы закон (карар) белән, Татарстан Республикасы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Президенты карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән очраклардан тыш. |
| 8 | Кредит бурычларын түләү | 2014-2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасы кысаларында кредит бурычларын түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү | Финанс-икътисадый нигезләү, Субсидияләр бирү өчен Министрлыкка каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бүленә, Субсидияләр күләме бюджет турындагы закон (карар) белән, Татарстан Республикасы Президенты карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән очраклардан тыш. |
| 9 | Ремонт эшләренә бәйле рәвештә яисә оешманы үзгәртеп кору яки бетерүгә бәйле рәвештә дәүләт яки социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә Учреждение эшчәнлеген туктатып тору | 2014-2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасы кысаларында дәүләт яки социаль хезмәтләр күрәтү өлешендә Учреждение эшчәнлеген туктатып тору, Учреждениене үзгәртеп кору яки бетерү, Учреждение хезмәткәрләре санын яки штатын кыскартуга бәйле чараларга чыгымнарны гамәлгә ашыру | Чыгымнар сметасы һәм финанс-икътисадый нигезләү, Субсидияләр бирү өчен Министрлыкка каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бүленә, Субсидияләр күләме бюджет турындагы закон (карар) белән, Татарстан Республикасы Президенты карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән очраклардан тыш. |
| 10 | Учреждение белгечләре хезмәте өчен түләү | 2014-2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасы кысаларында Учреждение белгечләренә | ЗП= ∑ (ЗПi * Т *К * ЧС), биредә<br><br>ЗПi – i – нче белгечнең хезмәт хакы, сум. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | хезмәт хакы түләүгә бәйле чыгымнарны гамәлгә ашыру | ЧС – белгечләрнең саны, кеше.<br>К – хезмәткә түләү өчен исәпләнгән түләүләр (%),<br>Т – белгечләр эшли торган айлар саны. |

Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджеты акчалары торган субсидияләрне бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә 2 нче кушымта
________________ № _________

Форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына

Татарстан Республикасы бюджетыннан Субсидия бирүгә гариза

_______________________________________________________________
*(оешма атамасы)*

Татарстан Республикасы бюджетыннан Субсидия бирүдә катнашу өчен түбәндәге мәгълүматлар һәм документларны тапшыра:

_______________________________________________________________
*(ИНН/КПП, ОГРН)*

_______________________________________________________________
*(дәүләт теркәве датасы)*

_______________________________________________________________
*(Түләү өчен банк реквизитлары)*

_______________________________________________________________
*(Юридик затның адресы)*

_______________________________________________________________
*(Фактта урнашкан адресы*)

_______________________________________________________________
*(E-mail, телефон, факс)*

_______________________________________________________________
*(Җитәкчесенең фамилиясе, исеме, ата исеме; телефоны)*

_______________________________________________________________
*(Веб-сайт, социаль челтәрләр)*

_______________________________________________________________
*(Субсидия исеме)*

Шушы заявкада һәм аңа теркәлә торган документларда булган мәгълүматларның дөрес һәм тулы булуын раслыйм.

Тәртиптә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетыннан Субсидия бирү шартлары белән таныштым.

Заявкага түбәндәгеләр теркәлә:

| т/с | Документ исеме | Саны | |
|---|---|---|---|
| | | данә | бит |
| . | | | |
| . | | | |
| . | | | |
| . | | | |
| . | | | |
| . | | | |
| . | | | |
| . | | | |

Җитәкче ______________ _______________________ ________________
(имза) (тулы имза) (дата)

мөһер урыны

Баш бухгалтер
(булган очракта) ______________ _________________________ __________________
(имза) (тулы имза) (дата)